| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.08.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2082** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 4 октябрендәге 2417 номерлы карары белән расланган Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында һәм субсидияләрне федераль бюджеттан 2022 елда бирү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 05 апрелендәге 590 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 4 октябрендәге 2417 номерлы карары белән расланган Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә(Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 декабрендәге 3088 номерлы , 2021 елның 29 декабрендәге 3427номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 959 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- сайлап алуда катнашучы экстремистлык эшчәнлегенә яки терроризмга катнашы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, яисә аларның массакүләм юк итү коралы таратуга катнашы булуы турында белешмәләре булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел (мондый таләпләр хокукый акт белән каралган очракта).»

1.2.Нигезләмәнең 7.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.1 Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының субсидия алучы тарафыннан үтәлешен , шул исәптән аларны билгеләнгән тәртиптә бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, мәҗбүри тикшерә.

Муниципаль финанс контроле органы («Зеленодольск муниципаль районы контроль - хисап палатасы» муниципаль учреждениесе) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.».

1.3. Нигезләмәнең 7.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.3 Субсидияләр биргәндә, аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча тикшерүләрне, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органы («Зеленодольск муниципаль районы контроль - хисап палатасы» МУ) тарафыннан тикшерүләрне гамәлгә ашыруга субсидияләр алучыларның ризалыгы тора. Күрсәтелгән ризалык килешү турында әлеге шартны үз эченә алган субсидия бирү турында килешүне имзалау белән белдерелә.».

1.4.Нигезләмәгә кушымтаның 6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Әлеге килешүне имзалау белән Субсидия алучы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органы тарафыннан («Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы»МУ) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгын белдерә.».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1061673000993 ИНН 1648017863 КПП 164801001
Р.06-11648/05